**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске-Тәрбит авыл җирлегенең Иске-Тәрбит торак пунктында**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«29» октябрь, 2019ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске-Тәрбит авыл җирлегенең Иске-Тәрбит торак пунктында граждannар җыены КАРАР КЫЛДЫ :

1. 2020 елда үзара салым акчаларын Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске-Тәрбит авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә алып барырга.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

а) *җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру*:
- авыл җирлеге торак пунктларындагы санкцияләнгән һәм санкцияләнмәгән чүплекләр территорияләрен чистарту;
- материаллар сатып алып күперләрне ремонтлау;

б) *җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру*:
- материаллар сатып алып, су челтәрләрен ремонтлау;

в) *җирлектәге торак пунктлар чикләрендәге җирле автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге* ;
- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;
- җирлектәге торак пунктлар чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;

г) *ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;*
- зиратларны чистарту һәм төзекләндерү,

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске-Тәрбит авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Граждannар җыенында рәислек иткән,
Иске-Тәрбит авыл җирлеге башлыгы: В.Г.Тимофеев